**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 24.03. 2020** **№ 320**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең составын һәм нигезләмәсен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы” Федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 нчы елның 28 нче гыйнварендәге 47 нче номерлы “Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәне раслау турындагы” карарына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндә китерелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең составын (килешү буенча) (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең нигезләмәсен (2 нче кушымта);

2.Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- 2018 нче елның 1 нче июнендәге 1153 нче номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә федераль милектәге, муниципаль торак фондындагы урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш һәм шәхси торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең Нигезләмәсен раслау турында»;

- 2018 нче елның 17 нче декабрендәге № Башкарма комитетның 2018 нче елның 1 нче июнендәге 1153 нче номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә федераль милектәге, муниципаль торак фондындагы урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш һәм шәхси торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең Нигезләмәсен раслау турындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

1 нче кушымта
Расланган
ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 мартындагы 320 нче номерлы Карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Хәкимуллин Рамил Фатих улы | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча урынбасары, комиссия рәисе; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Мингазов Салават Марат улы | Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе, комиссия рәисенең урынбасары; |
| Фатыхов Денис Зәкәрия улы | Район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы, комиссиянең секретаре; |
| Сабитов Рамил Фаил улы | Татарстан Республикасы БТИ АЖ Биектау бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Арефьева Елена Николаевна | ТР Дәүләт торак инспекциясенең үзәк инспекторлык бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Гыйсмәтов Рамил Ринат улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Үзәк территориаль идарәсенең махсус инспекциясе начальнигы (килешү буенча); |
| Аликов Егор Иванович | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Биектау муниципаль районында күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| Шәмсетдинов Илдар Мансур улы | Ростехнадзорның Идел буе идарәсенең Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Салкова Эльвира Валентиновна | Роспотребнадзорның Биектау, Арча муниципаль районнары буенча территориаль бүлеге начальнигы (килешү буенча); |

Комиссия эшенә кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә проект документациясенә экспертиза бәяләмәләрен һәм (яисә) инженер эзләнүләре нәтиҗәләрен әзерләү хокукына аттестацияләнгән экспертлар һәм башка затлар җәлеп ителергә мөмкин (килешү буенча).

Комиссия эшенә җәлеп ителәләр:

- торак урын милекчесе (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат) (киңәш бирү тавышы хокукы белән);

2 нче бүлек
Расланган
ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 мартындагы 320 нче номерлы Карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

1. Урынны торак урын, торак урынны һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмә (алга таба Нигезләмә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссиясен төзү һәм аның эшләве тәртибен (алга таба - Комиссия) билгели.

2. Ведомствоара комиссиясе үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясенең федераль законнары һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актлары, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварендәге 47 номерлы «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәне раслау турындагы» карары, гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары, әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Нигезләмәнең гамәли көче Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан эксплуатациядә булган торак урыннарга аларның милек формасына бәйсез рәвештә кагыла.

4. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген туктату, әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук Ведомствоара комиссиянең персональ составын үзгәртү Биектау муниципаль районы башкарма комитетының тиешле карарын кабул итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Комиссия утырышлары үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне карау турында гаризалар кергән саен уздырыла.

6. Комиссия вазифасына гамәлдәге законнар билгеләгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны

торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану кирә.

7. Комиссия Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләсен, торак урын милекчесенең, хокук иясенең яисә гражданның (яллаучының) гаризасы нигезендә яки дәүләт күзәтчелеге (контроле) органнарының үз компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча бәяләмәсе нигезендә, яки Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 нчы елның  21 августындагы 1082 нче номерлы «Ирекле иминиятләү механизмын файдаланып, иминият хисабына зыянны каплау һәм Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет чаралары хисабына тапшырыла торган ярдәм хисабына Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан гражданнарның торак урыннарына китерелгән зыянны каплауны оештыру программасы кысаларында каплауга каралган зыянның күләмен билгеләү методикасын, ирекле иминиятләү механизмын файдаланып, Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан гражданнарның торак урыннарына китерелгән зыянны каплауны оештыру программасы кысаларында китерелгән каплауга каралган зыян китерелгән торак урынга экспертиза үткәрү Кагыйдәләрен раслау турындагы, һәм урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турындагы" карары нигезендә үткәрелгән экспертиза бәяләмәсе нигезендә, торак урынның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 нчы елның 28 нче гыйнварендәге 47 нче номерлы карарының 47 пунктында каралган тәртиптә карарлар кабул итә.

8. Комиссия әгъзалары: Комиссия утырышларында катнашырга, карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда һәм карарлар эшләүдә катнашырга; утырышта катнашу мөмкин булмаганда, алдан ук бу турыда Комиссия секретарена хәбәр итәргә; кирәк булган очракта, комиссия секретарена көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә җибәрергә бурычлы.

9. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы: үз компетенциясе чикләрендә гражданнарның имин яшәү тирәлеген тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә барлык дәрәҗәләрдәге башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру, координацияләү һәм камилләштерү өчен кирәкле карарларны кабул итәргә; дәүләт, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан торак йортларның (торак урыннарның) торышы турында кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга; уртак эштә катнашу өчен милек формасына бәйсез рәвештә барлык дәрәҗәләрдәге башкарма хакимият органнары, предприятиеләр һәм оешмалар вазыйфаи затларын һәм белгечләрен җәлеп итәргә; торак урыннар милекчеләрен һәм яллаучыларын торак урыннарны тикшергәндә комиссиядә катнашуга җәлеп итәргә; Комиссия тарафыннан ахыргы карарны кабул

итү өчен кирәкле мәсьәләләргә төгәллекләр кертү максатыннан торакчылардан һәм яллаучылардан (арендаторлардан) сораштыру үткәрергә; гариза бирүчеләрне, яллаучылар һәм торак урын милекчеләрен, оешмалар вәкилләрен аларның гаризалары каралганда Комиссия утырышына чакырырга;

10. Комиссия утырышы комиссия рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан җыела һәм Комиссия әгъзаларының кимендә 2/3 булган шартта тулы хокуклы дип таныла.

11. Ведомствоара комиссиясе рәисе түбәндәгеләрне башкара:

1) Ведомствоара комиссиясе белән гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

2) Ведомствоара комиссиясе утырышларының датасын билгели;

3) Ведомствоара комиссиясе утырышларын даими чакырылуын тәэмин итә;

4) Ведомствоара комиссия әгъзаларының тәкъдимнәреннән чыгып, ведомствоара комиссиясе утырышының көн тәртибен төзи һәм раслый;

5) Ведомствоара комиссиясе кабул иткән карарларның үтәлешенә һәм тормышка ашырылуына гомуми контролен гамәлгә ашыра;

6) Ведомствоара комиссия утырышларында рәислек итә, аның гамәлләрен координацияли, тәкъдимнәр бирә;

7) Ведомствоара комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча документлар имзалау хокукына ия.

12. Ведомствоара комиссиясе рәисе урынбасары ведомствоара комиссиянең оештыру-методик эшен башкара, комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара.

13. Ведомствоара комиссиясе секретаре:

1) Ведомствоара комиссиянең чираттагы (чираттан тыш) утырышын уздыру датасына кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча аның әгъзаларына ведомствоара комиссия утырышы көне, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә;

2) Ведомствоара комиссиясе утырышларын оештыруга бәйле эш уздыра;

3) Ведомствоара комиссиясе утырышына документлар пакетларын әзерли;

4) Ведомствоара комиссиясе карарларын кабул итү өчен өстәмә документлар тапшыру кирәклеге турында соратулар әзерли һәм җибәрә;

5) Ведомствоара комиссиясе утырышлары беркетмәләрен, ведомствоара комиссиясе беркетмәсеннән өземтәләрне, актларны һәм ведомствоара комиссия бәяләмәләрен рәсмиләштерә;

6) Ведомствоара комиссиясенә ведомство буйсынуындагы мәсьәләләр буенча Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының карарлары (күрсәтмәләре) проектларын әзерләүне гамәлгә ашыра;

7) гариза бирүчеләргә Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карарларыннан өземтәләр, ведомствоара комиссиясе утырышлары беркетмәләреннән өземтәләр, ведомствоара комиссиясе актлары һәм бәяләмәләреннән өземтәләр әзерли һәм җибәрә.